**Аңлатма язуы**

Балалар бакчасында рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү программасы (алга таба программа) “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт стандартлары”на (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 17.10.2013 елда 1155 нче карары) нигезләнеп төзелде.

Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән

Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне татар теленә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

“Татарча сөйләшәбез” дип аталган методик комплект балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. Комплектка, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, методик кулланма, күрсәтмә һәм таратма әсбаплар, аудио һәм видео материаллар, балалар өчен эш дәфтәрләре туплап бирелгән. Методик комплектлар өч яшь төркеме өчен әзерләнгән һәм аларның барысы да “Татарча сөйләшәбез” дип исемләнә. Бүгенге социолингвистик ситуациядә һәм гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары тормышка ашу кысаларында рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү буенча яңа укыту-методик кулланмалар җыентыгы килеп басты.

Балалар татар телен, мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.